## КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге составына керүче Левашево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «2020 елда Левашево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә:

- җирлекэчендәге юлларны караптоту;
- контейнер мәйданчыкларытөзү;
- чүп контейнерлары сатыпалу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 293 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 178 кеше.

Халык җыенында катнашучыларның үзара салым кертү күләмен 400 сумнан 500 сумга кадәр арттыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, халык җыенында катнашучы гражданнарның тавышларытүбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 178 кеше,

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге составына керүче Левашево авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.

2. “2020 елда Левашево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә:

- җирлекэчендәге юлларны караптоту;
- контейнер мәйданчыкларытөзү;
- чүп контейнерлары сатыпалу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ        КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны Левашево авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче        С.А.Демидова